وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклапябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!


# Дин вә Мәгыйшәт

№20 (117). 30 декабрь 2011 / 5-сафәр-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



*Биектау мөхтәсибе:* "Халык хезмәтебезне хуплау белән каршы алды" ▷2◁



Элек һәм хәзер ▷3◁



2012 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр ▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ЯТИМНӘРНЕ ЦИРККА АЛЫП БАРДЫЛАР

24 декабрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге, Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдин һәм мөхтәсибәтнең яшьләр белән эшләү бүлеге вәкиле Алан хәзрәт Панарин белән берлектә Яшел үзән районының Норлат балалар йортындагы ятимнәрне циркка алып баруны оештырды.

***Чыганак: www.dumrt.ru***

### ШАХМАТ ЯРЫШЛАРЫ УЗДЫ

25 декабрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте РИУда мәчет имамнары һәм дини уку йортлары мөгаллимнәре арасында шахмат ярышлары үткәрде. Әлеге чарада Әниләр, Солтан, Ал, Фәрхәд, Ислам, Ризван, Әҗем мәчетләре һәм Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә катнашты.

I урынга РИУның ислам хокукы кафедрасы мөдире Мөхәммәтморат хәзрәт Моратов лаек дип табылды. II урын РИУның филология һәм илләр өйрәнү кафедрасы мөдире Тимур хәзрәт Шәйхуллинга бирелде. III урынны Солтан мәчете имамы урынбасары Тимерхан хәзрәт Фәттахов алды.

Җиңүчеләргә медальләр, дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

***Чыганак: www.dumrt.ru***

### ТАҖИКСТАН ВӘКИЛЛӘРЕ РИУДА БЕЛЕМ ӨСТӘЯЧӘК

Таҗикстанның әйдәп баручы ислам югары уку йорты вәкилләренең Россия ислам университетына визиты кысаларында ике арада хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды.

Әлеге документны РИУ ягыннан вуз ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, Таҗикстанның ислам университеты ягыннан анализ, контроль һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге җитәкчесе Абдуманнон Сәедов имзалады.

Хезмәттәшлек кысаларында студентлар һәм профессорлар, укытучылар алмашу, Таҗикстан укытучыларының ислам дисциплиналары буенча квалификациясен күтәрү, уртак мәгариф һәм фәнни проектларны үстерү күздә тотыла.

***Чыганак: www.e-riu.ru***

### КАНИКУЛ ВАКЫТЫНДА – "ИЗГЕ ЮЛ" МӨСЕЛМАН ЛАГЕРЕ

Кышкы каникул көннәрендә (2-10 гыйнвар) егетләр өчен "Изге юл" мөселман лагере эшләячәк. Ул Исхак хәзрәт исемендәге милләтара мәдәни-агарту үзәге тарафыннан РИУ белән бергәлектә оештырыла.

Лагерь Казанның Кабан арты мәчете мәдрәсәсендә 9-15 яшьлек яшүсмерләрне җыеп үткәрелә.

Балалар ялы мавыктыргыч шөгыльләргә бай булачак. Биредә РИУның махсус әзерләнгән шәкертләре ял итүчеләргә ислам нигезләрен аңлата, Коръән уку серләренә төшендерә, гарәп язуын өйрәтә алачак. Эш рухи-әхлакый тәрбия бирү һәм сәламәт яшәү рәвешенә күнектерү юнәлешендә алып барылачак.

Лагерь азагында имтиханнар да үткәрелеп, балаларга "Изге юл" кышкы мөселман лагеренда дини белем алганлыкларын раслаучы сертификатлар тапшырылачак, истәлекле бүләкләр таратылачак.

***Чыганак: www.isxak.ru***

# ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ: 2011 ЕЛДА

**Татарстан мөселманнарының 13 апрельдә үткән чираттан тыш V корылтаенда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең көнүзәк мәсьәләләре яктыртылды. Сигез ай ярым вакыт эчендә шактый гына нәтиҗәле эшләр башкарылды. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре, имам-мөхтәсибләр, казыйлар, республикабыз имамнары белән бергәлектә, куелган максатларга ирешелде.**

Идеологик эшчәнлек көчәйтелде: Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең, мөхтәсибәт һәм мәхәлләләрнең Уставлары Россия Федерациясенең законнар җыелмасы белән яраклаштырылды. Эшчәнлек Коръән һәм Сөннәткә, хәнәфи мәзһәбенә туры китерелеп башкарылды. Мөфтиятнең оештыру документларына кертелгән үзгәрешләр Россиянең Татарстан буенча Юстиция министрлыгы идарәсендә теркәлде. Мөхтәсибәтләр һәм мәхәлләләрнең оештыру документларына кертелгән үзгәрешләрне теркәү өчен, Диния нәзарәте Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Юстиция министрлыгы идарәсенә гаризалар әзерләү һәм җыеп бирүне контрольдә тота һәм тиешле дәрәҗәдә башкарып килә. 2011 елның 1 декабренә өч йөзләп мәхәллә тикшерү үтте.

Кадрлар бүлеге хезмәткәрләре яңа штатлы расписание булдырды. Россия Федерациясенең "Хезмәт турында"гы Кодексы нигезендә, ТР мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләренең һәм имам-мөхтәсибләрнең шәхси эшләре җыелды һәм рәсмиләштерелде. Аттестация үткәрү өчен, Татарстан районнарының имам-хатыйблары арасында анкета тутыртылды, шуның нигезендә республикабыз имам-хатыйбларын барлаган электрон база төзелде.

Дини экстремизм, ксенофобия һәм исламофобиягә каршы тиешле чаралар күрелде: "Ислам террорчылыкка каршы" дип исемләнгән конференция, "Ислам - тынычлык дине" дип аталган митинглар үткәрелде, "Экстремизмга юл юк!" айлыгы кысаларында мөселман уку йортларында, мәчет-мәхәлләләрдә вәгазьләр укылды. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы республикабызда таратыла торган дини әдәбиятның хәнәфи мәзһәбенә туры килү-килмәвенә ачыклык кертте һәм тиешле карарлар чыгарды.

Массакүләм мәгълүмат чаралары белән нәтиҗәле эш башкарылды. Диния нәзарәтенең яңа сайты - www.dumrt.ru булдырылды. Россиядә беренчеләрдән булып, атналык мөселман газеталары - рус телендә "Умма" һәм татар телендә "Дин вә мәгыйшәт" газеталары дөнья күрә башлады. Социаль челтәрләрдә мониторинг үткәреп, мөфтиятнең эшчәнлеген яктырту һәм киң массага җиткерү өчен махсус кешеләр билгеләнде. Телевидениедә дин әһелләре ешрак чыгыш ясый башлады. 2012 елда "Tatar radiosi" һәм "Яңа гасыр" радиоларында тапшырулар әзерләү күздә тотыла.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте шулай ук мәгариф-агарту эшләренә дә зур урын биреп килә. Түгәрәк өстәлләр, конференция, төрле иҗтимагый чаралар оештырып, аларга Татарстаннан һәм Россиядән генә түгел, БДБ илләреннән дә зыялылар, фән эшлеклеләре, дәүләт органнары, иҗтимагый оешмалар җәлеп ителде.

2011 елда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр сәясәте әзерләнде. Ел дәвамында "Алтын урта" клубы актив эшләп килде, Болгарда I Проектлар мәктәбе үтте. Декабрьдә "Мөселман яшьләре берлеге" төбәкара иҗтимагый оешмасы теркәлде. Чит илләрдә укучы студентлар да игътибарсыз калмады. Каникул көннәрендә алар белән очрашу оештырылды, киләчәктә аларны Татарстанда эш белән тәэмин итү мәсьәләләрен чишү буенча да фикер алышынды.

Сентябрь аеннан Казанда имамнарның квалификацияләрен күтәрү үзәге эшли башлады, күп кенә район имамнары әлеге курсларда белемнәрен дә камилләштерүгә иреште. Хәнәфи мәзһәбенә туры килә торган уку-укыту программалары әзерләнде, мәдрәсә һәм мәчет каршындагы курслар өчен һәм мөселман лагерьларын үткәрү буенча яңа программалар әзерләнде.

Диния нәзарәтендә нәшрият бүлеге оештырылды. Бүлек хезмәткәрләре Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин, Муса Бигиев кебек XX йөз дин тәгълиматчыларының хезмәтләрен җентекләп тикшереп, бүгенге көнгә яраклаштырып бастыру эшләрен башлады. Шулай ук нәшрият бүлеге дини әдәбият бастыру, аудиокитаплар, вәгазьләр әзерләүгә дә игътибарын юнәлтеп килә. Киләчәктә һәр мөхтәсибәт каршында Китапханә фонды оештырылачак.

Төзәтү колонияләрендәге мөселманнар да әлеге китаплардан файдалана алачак. Татарстанның җәзаларны үтәтү буенча Федераль хезмәте (УФСИН) белән элемтәдә тору бүлеге, колонияләрнең һәм төрмәләрнең җитәкчелеге белән, төзәтү учреждениеләре мәчетләрен ваһһаби китаплардан "чистартты". Колонияләрдә тоткыннар белән эшләү өчен махсус имамнар билгеләнде, Ураза һәм Корбан гаетләрендә төзәтү учреждениеләрендә бәйрәм чаралары оештырылды.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге "Апрель" тернәкләндерү үзәген үз канаты астына алды. Ятимнәр, мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен чаралар үткәрелде, авыру балаларны дәвалауга да даими рәвештә хәйрия акцияләре оештырылып килде.

Финанс эшчәнлеге үз эшен берничә юнәлештә алып бара. Имам-мөхтәсибләр һәм казыйлар хезмәт хакы ала башлады, якын киләчәктә мәдрәсә укытучыларына да хезмәт хакы түләү хәл ителәчәк. ТР мөселманнары Диния нәзарәте Уставының икътисад эшчәнлегенә өстәмәләр кертелде. Диния нәзарәтенең милке торгызылды һәм милеккә хокук бирә торган кирәкле документлар үз көченә кайтартылды. Киләчәктә имамнарның финанс мәсьәләләрен һәм матди проблемаларын чишү максатыннан, вакыф милке торгызылды. Мөфтият каршында Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе оештырылды, аларның ярдәме белән I Республикакүләм ифтар ашы узды.

Үткәрелгән барлык чаралар да физик һәм юридик затларның иганә акчаларына, Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгарифенә булышлык фонды ярдәмендә үткәрелде. Шул акчалар хисабына хезмәт хакы түләнде, коммуналь чыгымнар капланды, Диния нәзарәте бинасында ремонт эшләре башкарылды, җәйге лагерь, түгәрәк өстәл, конференция, җыен, конкурслар, Татарстан мөселманнарының чираттан тыш V корылтае, хәйрия акцияләре оештырылды. Казан шәһәренең Тукай урамында урнашкан 3 нче йортта вакыф үзәге ачылды.

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# МӨСЕЛМАНЧА ЯҢА ЕЛ

**Яңа ел - балачактан ук истә калган, бер-беребезне котлап, ниндидер өметләр белән көтеп алынган көн. Бу көнне, гадәттә, кибеттән тәмтом алып кайтабыз, гаилә, туганнар белән булабыз. Әмма бу бәйрәмне үткәрү турында ислам дине галимнәре ни фикердә, нәрсәләр киңәш итә икән?**

Быелның 26 ноябрь көне кайберәүләребез өчен сизелмичә узып китте. Тарихка күз салсаң, бу көнне пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) 622 елны Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт ясый һәм шушы көннән алып ислам календаре буенча елның беренче көне санала башлый. Әлеге беренче айның исеме - Мөхәррәм. Бу айны Аллаһы Тәгалә аеруча сугышларны, үч итүләрне һәм башка төрле кан коюларны тыйган, чөнки Мөхәррәм - тәүбә һәм гыйбадәт кылу ае.

Шушыларны белеп, искә алып, алдагы якынлашып килүче 31 декабрь көнен мөселман кешесе, гаиләсе ничек каршы алырга тиеш? Бу көн берәр үзенчәлеккә ияме яисә ул гадәти көннәр санына керәме?

***(Ахыры 4 нче биттә.)***



# Каш ясыйм дип күз чыгармыйк!

**Мәктәп укучысына югары математиканы өйрәтмиләр. Математика саннарны өйрәнү, кушу-алу, тапкырлау-бүлүдән башлана. Әгәр балага катлаулы формулалар өйрәтә башласаң, фәнгә карата нәфрәт кенә туачак. Галимнәр гади халык белән сөйләшкәндә фәнни терминнарны сирәгрәк куллана, катлаулы проблемаларны үз эчендә хәл итә.**

Әлеге күренешне юкка гына сурәтләмәдем. Мөселман өммәтендә шундыйрак хәл көннән-көн арта бара. Гади халык дип әйтик, диннең "д" хәрефен дә белмәгәндә, газета-журнал битләрен тутырып, радио-телевидениене шаулатып, "ваһһабилар" дигән сүзләр чыкты, террорны мөселманнар белән бәйли башладылар, мәзһәбләр арасындагы аермалар, төрле сораулардагы каршылыклар турында бәхәсләр башланды. Ашап туйгач, "Амин" әйтеп куюдан артыгын белмәгән халыкның күзе шар булды: әби-бабадан килгән динебезнең тагын нинди яклары ачылыр?

Авылда (район, шәһәрдә) бер-бер артлы яулык бөркәнгән, атлаганда җирне себереп баручы озын итәкләр кигән, күзләрен өскә күтәреп тә карамаучы кызлар саны ишәя башлады. "Түбән очта яшәүче Салихның кызы: "Телевизор шайтаннан ул, карамагыз", - дип әйтә дигән чышын-пышын аптырау сүзләре китте. Күрше авыл егете укырга киткән җиреннән көрәк кадәр сакал үстереп кайткач һәм мәктәптә бергә укыган кызлары белән дә исәнләшми башлагач, халык тагын да борчуга калды: менә нишләтә икән ул дин!

Күп тә үтмәде, икенче бер авылда шундый "көрәк сакаллылар" мәчеттә яши башлаган икән, дигән сүз чыкты. Дөрес, кемдер: "Яшәмиләр, ә көн саен җыелып нидер сөйләшәләр", - дип төзәтте. Шул арада берсе тагын: "Телевизордан күрсәткән террорчылар булмасын тагын! Ваһһабилардыр әле!" - дип тә ярып салды.

Тыныч кына яшәп ятучы кайбер гаиләләрдә ата-ананы төн йокысыннан калдырган борчу туды. Әнә бит, шәһәрдә укып ятучы бердәнбер малайлары намаз укый башламакчы, икенче берәүләренең кызы: "Яулык ябам", - дигән була. Хәзер, ди, менә! Бөтен урамның бармак төртеп көлүе, чышын-пышын сөйләвенә түзеп торасы юк - башкалар нинди, безнең балалар да шундый булырга тиеш! Тәртипле булсыннар, тыйнак киенсеннәр - артыгын маташмасыннар. Әнә бит, Гөлбикәнең кызы бер мөселман егете белән танышып, ике ай йөргәннән соң кияүгә чыкты да өйдә бикләнеп яши башлады. "Мин үз балама андый киләчәк теләмим!", "Намаз укый башлар да, Яңа ел, туган көн бәйрәм итү юк, дип, Салих кызы кебек, оятка калдырып бетерер!"

Искиткеч бу, җәмәгать! Юк, искиткеч түгел, коточкыч! Шулкадәр гүзәл, камил динебезне нишләттек?! "Ислам динен тотабыз" дип тырыша-тырыша башкаларда аңа карата нәфрәт тудыру - бу нәрсә? Икейөзлелекме, кяферлекме, гөнаһмы, ялгышумы, нәрсә бу?

Курыкканга куш, койрыгы белән биш, диләр. Башына бәла төшкәч кенә: "Ярдәм ит, Ходаем!" - дип ялвара башлый торган халык күңелендә вәсвәсә туды: ата-бабаларыбыз тоткан динне белмәгәнбез генә, ахры...

Шул арада муллалар үзара бәхәсләшә башлады, моңа кадәр колакка ишетелмәгән "мәзһәб" дигән сүзне еш кабатлый киттеләр, гошер сәдакасы өчен дип мәҗбүриләп бәрәңге җыеп йөргәч, аларга булган бер тамчы хөрмәт тә парга әйләнеп очты...

Яшьләр дингә килә, дип сөенәбез. Ләкин ни өчен дингә килгән яшьләребез артыннан совет заманында үскән коммунист әти-әниләре дә тартылмый? Әгәр яшьләр ислам кануннарын дөрес үти икән, аларга карата соклану туарга тиеш түгелме? Мөселман кешесе әти-әнисенә аерата зур хөрмәт һәм ярату белән карарга, аларның фикерен аяк астына салып таптамаска, нинди генә караш белән яшәсәләр дә, аларны кире какмаска тиеш бит. Бу турыда хәдисләр, гыйбрәтле хикәятләр күпме! Ислам тотучы кеше боларны белә булыр. Аларның күркәм сыйфатларын күреп башкалар да сокланырлык булырга тиеш. Аларны күреп сокланган кеше исламга тартылмый мөмкин түгел...

Берәр зур эш башлаганда, кечкенәдән гадәткә кергәнчә, "бисмиллә" дип әйтеп куюдан артыгын белмәгән гади халыкка ислам диненең кеше аңлап бетермәслек якларын үзебезчә аңлатып, катлауландырып, булмаган тыюларны да ясап, нәфрәт кенә тудырмыйбызмы? "Мин мөселман", - дип көне-төне намаз һәм догалар укып, әти-әнисе муенына яшәп утыручы яшьләребез хәерле гомер кичерәме? Савaплары күп булырмы?..

Бер гаилә дә эчке проблемаларын урамга чыгып кычкырмый! Мөселман өммәте икәнбез, без дә үз пробелмаларыбызны эчтә хәл итәргә тиеш. Гаиләдәге кагыйдәләрне һичкем күршеләргә кереп таләп итә алмый - моңа соклану аша тартырга, өйрәтергә мөмкин, ә таләп итәргә түгел! Чит йортка үз таләпләреңне куеп булмый - кеше күңеленә дә таләпләр куя алмыйсың.

Балаларга фәнне өйрәтер өчен башта соклану, кызыксыну уяталар. Беренче дәресләрдән үк нәфрәт туган фәнне гомергә дә өйрәнә алмыйсың. Әгәр исламга карата шундый мөнәсәбәт туса - белмим, моның өчен кем түләргә тиеш?

"Кеше өчен түгел, үзебез өчен тырышабыз, Кыяматтә үзебез генә булабыз", - диючеләр дә булыр. Әмма үз гамәлләребез үз җилкәбездә булачак бит. Безнең гамәлләр аркасында исламга шикләнеп яки нәфрәтләнеп (әстәгъфируллаһ!) караучылар өчен җавапны да үзебез тотарбыз.

Ихлас күңелдән кылган яхшылык кешенең йөзендә нур уята. Бернинди ясалмалык та, арттыру да, киметү дә, булмаганны бар итәргә тырышу да кирәкми. Йөздәге нур - күңелдән, ният-гамәлләр ихластан булырга тиеш. Шул очракта сиңа сокланып карарлар. Чын мөселман шундый була!

*Таңсылу РӘХИМОВА*

# Суд Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрендә ял итүгә каршы түгел

**Россиянең Югары суды Башкортстанда Корбан һәм Ураза бәйрәмнәрендә ял итүне законлы дип тапты. "РИА Новости" хәбәр итүенә караганда, Башкортстан Дәүләт Җыены дәгъвасына җавап буларак, берничә ай элек кабул ителгән әлеге бәйрәм көннәре ял көне түгел, дигән карар юкка чыгарылды.**

Белгәнебезчә, агымдагы елның сентябрь аенда Башкорстанда яшәүче Сергей Дулов дигән бер журналист мөселман бәйрәмнәрендә ял итәргә теләмәве белән танылды. Сергей Дулов ислам дине бәйрәмнәрендә ял итү Россия Конституциясенә, Хезмәт Кодексына һәм кайбер Федераль Законнарга каршы килә, дип саный. Башкортстан судларында яклау тапмагач, ул Россия Югары судына мөрәҗәгать итә һәм теләгәненә ирешә: Россия Югары Суды аның дәгъвасын канәгатьләндерә. Чөнки РФ Хезмәт Кодексы "тарихи, милли һәм башка традицияләргә бәйле хезмәт мөнәсәбәтләре"н көйләми икән. Бу уңайдан федераль карар гына көчкә ия. Димәк, төбәкләр Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрендә ял итүне үзләре генә хәл итә алмый.

26 августта Россия мөселманнары арасында зур бәхәсләр уяткан бу мәсьәлә буенча Башкортстан депутатлары РФ Дәүләт Думасына илебезнең мөселманнар күпләп яши торган төбәкләрендә Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрендә ял итү турында закон проекты белән чыкты.

Бу уңайдан, 27 сентябрьдә Казанда уздырылган республика мәчетләре мөгаллимнәренең I Киңәшмәсендә ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев Россия Югары суды карары белән килешмәвен белдергән иде. Ул: "Без республикада инде моннан дистә елдан артык элек Корбан гаетен закон нигезендә ял көне дип билгеләдек. Менә узган ел гына Татарстан Дәүләт Советында яңа закон кабул итеп, Ураза гаетен дә рәсми ял көне дип игълан иттек. 922 елның 21 маенда Бөек Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми дәүләт дине итү турындагы датаны шулай ук законга кертеп куйдык. Әмма бу арада куанычлы гамәлләргә тап төшә башлады. Россиянең Югары суды ил субъектларының үз бәйрәмнәрен булдыра алулары законсыз, дигән карар чыгара. Башкортстан һәм Татарстан парламентлары моңа ризасызлык белдереп, Россия җитәкчелегенә мөрәҗәгать итте. Бу көннәрдә әлеге мәсьәлә



карала. Һичшиксез, Россия законына үзгәрешләр кертелергә һәм төбәкләр үзләренең бәйрәмнәре турында законнарны кабул итәргә тиеш. Минемчә, бу мәсьәләгә ачыклык керер, ул уңай хәл ителер дип ышанырга кирәк. Конституцияне бозарга беркемнең дә хакы юк. Президентның да, министрларның да, депутатларның да", - дигән иде ул.

"РИА Новости" биргән мәгълүматларга караганда, Башкортстанда Корбан һәм Ураза бәйрәмнәрендә ял итү законы 1992 елдан бирле гамәлдә.

*Айзирәк ГӘРӘЕВА*
*Чыганак: www.intertat.ru*

*Биектау МӨХТӘСИБЕ:*

# "Халык хезмәтебезне хуплау белән каршы алды"

**Тәлгать Эдуард улы Гайфуллин 1984 елның 20 октябрендә Кукмарада дөньяга килә. Ул бер айлык сабый булганда, әти-әнисе, ике яшьлек абыйсы белән Дәрвишләр бистәсенә күченеп тора башлый. Шушы бистәдә балалар бакчасына йөреп, аннан 11 нче татар гимназиясен тәмамлый.**



- Мәктәп елларында татар телен яхшылап үзләштердем, әмма гаиләдәге тәрбия дә зур йогынты ясагандыр. Дәү әнием намаз укый башлау белән, минем дә күңелем исламга тартыла башлады. Дин гыйлемен яхшырак үзләштерү нияте белән 2001 елда РИУның әзерлек курсларына укырга кердем. Әмма ул гына җанымны тынычландыра алмады. Меңәр еллар мөселманнар үз гореф-гадәтләрен бүгенге көнгә кадәр саклап калган илгә барырга теләгем уянды, - ди Тәлгать хәзрәт.

Кечкенәдән спорт белән шөгыльләнеп, куйган максатларына ирешергә тырышкангадырмы, шул ук елны Төркия иленә барып, белем ала ул:

- Бер елга якын чит илдә тору авыр булса да, андагы укытучыларым дингә чын мәхәббәт уятты. Шул ук вакытта үз ватанымны сагыну хисләре мине кире Казанга алып кайтты. Укуымны "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә дәвам иттердем. "Бу дөньяның иң зур байлыгы - тәрбияле хатын", - диләр. Мин дә 2007 елны үз бәхетемне таптым. Шул елның башында хатыным Лилия белән никахлашып, туй ясадык. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен гаилә коручы кешегә бәрәкәтен Үзе бирә. Казан тирәсендәге авылларда йорт салырга җир эзләп йөргәндә искиткеч табигатьле, бик күркәм мәчете булган Озёрный бистәсенә тап булдым. Намаз вакытына туры килгән иде, мәчеттәге бабайлар белән танышканнан соң, аларның тәкъдиме белән имам булып хезмәт итә башладым. Чиксез Мәрхәмәтле Аллаһы Тәгалә безгә шул ук елның ахырында әти-әни булырга да насыйп итте. Тәүге улыбызга Габделкәрим дип исем куштык. Ул, чыннан да, Аллаһы Тәгаләнең юмарт бүләге иде. Хәзер без Озёрный бистәсендә торабыз, хәләл җефетем белән ике малай үстерәбез. 2007 елның март аеннан алып бүгенге көндә дә шушы бистәнең мәчетендә имам-хатыйб вазифасын алып барам. Быел май аенда Биектау районы мөхтәсибе итеп сайладылар. Минем өчен бу - бик көтелмәгән булды, зур җаваплылык таләп итә торган хезмәт бит ул, әмма шулай да риза булдым һәм тырышып башкарырга тотындым.

***- Сездә быел нинди эшләр башкарылды?***

- Быел җәй мәчетләрдә балалар өчен лагерьлар оештыра алдык. Районыбызның алты мәчетендә егетләр һәм кызлар өчен аерым җәйләүләр узды. Балалар бик теләп укыдылар, намаз укырга, дога кылырга, ислам диненең әхлак кагыйдәләрен өйрәнде. Әлеге эш-ниятебез халык тарафыннан зур хуплау тапты. Киләчәктә балаларның ялын оештыру буенча хезмәтебез тагын да киңрәк колач алыр, дип уйлыйбыз. Биектау бистәсендә яңа мәчет салына башлады. Беренче нигез ташын куйганда Коръән укып, тәкбирләр әйттек. Берёзка, Шәпше авылларында да төзү эшләре алып барыла, алар да озакламый мәчетле булыр, Иншә Аллаһ.

***- 2011 елның Рамазан ае кай ягы белән истә калды?***

- Районыбызның барлык мәчетләрендә дә диярлек авыз ачу мәҗлесләре оештырылды. Биектауның Җәмигъ мәчетендә, Озёрный, Чыпчык, Казаклар, Битаман авылларында узган мәҗлесләрдә катнаштым. Җәмигъ мәчетендә оештырылган ифтарда көн саен өч йөзгә якын кеше сый-хөрмәт күрде.

***- Эшегездә нинди дә булса кыенлыклар бармы?***

- Кадрлар мәсьәләсе - безне иң борчыганы. Яхшы имамнар, ярдәмчеләр җитми. Менә дигән проектларыбыз бар, шуларга алынырга теләүчеләр юк. Матди кыенлыклар да очрап тора.

***- Укытулар оештырасызмы?***

- Барлык мәчетләребез дә ял көннәрендә дини дәресләр үткәреп килә. Укырга теләүчеләр өчен яшь буенча бернинди дә чикләүләр юк, теләгән һәркем килә ала. Киләчәктә мәдрәсә оештырырга ниятлибез.

***- Яшьләр белән ни рәвешле эш алып барасыз?***

- Вәгазьләр белән чыгабыз, авылларга йөрибез. **www.vkontakte.ru** социаль челтәрендә үз төркемебез бар, анда яңалыкларны да, үгет-нәсихәтләребезне дә урнаштырып барабыз. Район газетасында да мәкаләләребез чыгып килә. 2012 елга эш планын бергәләп хәл иттек.

**- Сезгә киләчәктә дә Аллаһы Тәгалә зур хезмәтегезне башкаруда ярдәм итсен! Сабырлык, сәламәтлек, көч-куәт телибез!**

*Әңгәмәдәш - Нияз САБИРҖАНОВ*

**Революциягә кадәр татарларның берничә иҗтимагый оешмасы булган. Берсе - мәхәллә - дини ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен төзелгән оешма (анда дин эшләрен халык тарафыннан сайланып, хөкүмәт раслап, билгеләп куйган дин әһеле алып барган). Икенчесе - игенчеләр җәмгыяте, крестьян общинасы. Игенчеләр җәмгыяте ул - крестьян сословиесе үзидарә оешмасы. Татар халкының төп өлеше игенче булганлыктан, авыл җирендә яшәгәнлектән, тормыш шушы җәмгыять кысаларында барган.**

# ЭЛЕК һӘМ ХӘЗЕР

Татарлар шәһәрләрдә, руслар белән бергә, аерым очракларны исәпкә алмаганда, шәһәр сословиесе җәмгыятьләренә - сәүдәгәр (купец), мещан, һөнәрче җәмгыятьләренә кергәннәр, аларда төп сүзне күпчелекне тәшкил иткән христианнар әйткән. Авыл җирендә исә игенчеләр җәмгыятен дә, мәхәлләне дә тулаем татарлар тәшкил иткән.

Дин һәм милләт сүзе янәшә йөргән. Беренчедән, бу күренеш татарларның яшәү урыны белән бәйле. Бик аз авылларда гына башка милләт вәкилләре яшәгән. Икенчедән, Идел-Урал төбәгендә татарлар зур халык булсалар да, ил күләмендә алар азчылыкны тәшкил иткән. Христианнар арасында яшәгән татарларның мөселман икәнлекләре аермачык күренеп торган.

Моннан тыш, мөселманнар арасында феодаль элитаның аз санлы булуы, Пётр I нең морза, князьләрне крестьян сословиесенә әверелдерүе татар җәмгыятендә дөньяви белемнең үсешенә комачаулык иткән. Бездә руслардагы кебек дөньяви белемне үстерүче дворян катламы булмаган дисәк, ялгыш булмас. Кабат дворян статусын кайтарган морзалар яки бу югары катлам вәкиле статусына хәрби хезмәт яки чиновник карьерасы аша ирешкән кешеләр үзләре - ярлы, җирләре аз булган. Нәтиҗәдә, татарларның күпчелегенә дини-иҗтимагый аң хас булган.

Революциягә кадәр ир белән хатын, балалар һәм өлкәннәр арасындагы мөнәсәбәтләр, мирас, милек бүлү һ.б. һәммәсе дә шәригать кануннары буенча барган. Бердәнбер үтәлми торган пункт - шәригатьтә каралган җәзаларның кулланылмавы. Җинаятьчеләрне җәзалау Россия дәүләте законнары һәм суды карары буенча тормышка ашырылган. Дөрес, вак-төяк җинаятьләрне игенче җәмгыятьләре вәкилләреннән торган волость суды караган.

Без мәктәп-мәдрәсәләр дип сөйләгәндә шунысына да игътибар итәргә тиешбез: бу уку йортларында дин сабагы укытылса да, алар, беренче чиратта, милли башлангыч һәм урта мәктәп функциясен үтәгән. Чөнки ул вакыттагы укыту тәртибе һәм эчтәлеге халыкның ихтыяҗына туры килгән. XIX йөзнең икенче яртысында - XX гасыр башында рус-татар мәктәпләре, аерым мәдрәсәләр янында ачылган рус класслары күпмедер дәрәҗәдә шушы милли-дини мәгариф системасына яңа төсмер биреп, аларда өлешчә рус телен укытуны керткән. Монысы күбрәк хөкүмәт тырышлыгы белән барган. XX гасыр башында алдынгы карашлы, Европага йөз тоткан кешеләр, бигрәк тә сәүдәгәрләрнең финанс ярдәме белән җәдид мәктәпләре күбәеп, дөньяви фәннәрне укыту арткан. Бер үк вакытта дини белем бирү дә сакланган. Шулай итеп, кайчандыр дини генә булып тоелган уку йортларында дөньяви фәннәр, рус теле укытыла башлап, алар трансформация кичергән.

Ул замандагы иң мөһим мәсьәләләрнең берсе - мәчет-мәдрәсәләрне төзү, аларны карау. Узган гасырның 90 нчы елларында милли күтәрелешнең аерылгысыз бер өлеше булып күпләп мәчетләр төзү торды. Чөнки халык милләтне һәм динне күтәрүне янәшә куйды. XX йөз ахырында күпсанлы дини биналар сафка басты. Алар төзелгәч, бөтен халык мәчеткә йөрер сыман тоелды.

1917 елгы революциягә кадәр мәчет-мәктәп төзеткән татар аларны карап-ремонтлап торуны үз бурычы санаган. Чөнки шәригать шулай куша. Яңа буын вәкилләре бу биналарны аталары-бабалары төсе дип тә карап торган. Диния назәрәте дә, мәхәллә халкы да башка берәү мәчет-мәктәпне ремонтларга теләсә, мөтәвәллидән (төзегән кеше) рөхсәт сораган. Безгә бу тәртипне пропагандалап, яңарту бик тә мөһим.

Документларны өйрәнү шуны күрсәтә: мәдрәсәләрне тоту чыгымнарын аерым байлар күтәргән, аларда төрле төбәкләрдән килгән булачак шәкертләр - дин әһелләре укыган. Ә мәктәпләрне карау мәхәллә өстендә булган. Урта Идел буендагы авылларда бу мәсьәлә "кем күпме бирә ала" дигән принцип буенча сәдака җыеп кына хәл ителмәгән. Авыл халкы элек тә авыр яшәгән, чөнки хакимият салымны игенче хуҗалыкларның мөмкинлеген исәпкә алып түгел, үзенә күпме кирәк шулай салган, игенчеләрне авыр тормышка дучар иткән. Бик еш очракта авылдагы мәчетләрне, мәктәпләрне ремонтлау, аларны кышкы чорга утын, ягулык белән тәэмин итү өчен игенче җәмгыяте ресурслары файдаланылган. Бу түбәндәгеләрдә чагылган: җәмгыять урманын кисеп, утын әзерләү, яки җәмгыять җиренең бер өлешен вакытлыча арендага биреп, акча юнәлтү, яки җәмгыять кирәк-ярагына (янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, янгын каланчасын, язгы ташуда зыян күргән күперләрне яңарту, юлларны ремонтлау һ.б.) ел саен һәр хуҗалыктан мәҗбүри җыелган салымның (мир салымы) бер өлешен дини максатларга тоту яки дини ихтыяҗларны үтәү өчен үзара салым салу. Авылда өч-дүрт мәчет булса да шулай эшләнгән! Акча бүленгән.

Күрәбез, монда шәригатьнең генә түгел, ә бәлки игенчеләр җәмгыяте әгъзаларының үзара ярдәмләшүе мөһим роль уйнаган, мөселманнар җәмәгать мәсьәләләрен хәл итүдә кулланылган модельне киң кулланганнар. Мондый карарлар җәмгыять җыенында бердәм рәвештә кабул ителгән. Миңа калса, бүгенге көндә авыл халкының бай яшәмәвен исәпкә алганда, игенчелек белән шөгыльләнүче оешмалар бу мәсьәләләрдә ярдәм кулы сузарга тиеш. Ул вакытта игенче хуҗалыгының имана кишәрлеге булган. Бүген ул юк, игенче икътисади яктан әле мөстәкыйль түгел.

Чөнки сүз шушы коллективларда эшләүчеләрнең дини ихтыяҗларын канәгатьләндерү турында бара. Башка чара юк. Дини институтлар һәрвакыт халык хисабына яшәгән. Шулай булганда гына алар дәүләткә бәйле булмый, һәм финанс, һәм рухи мөстәкыйльлекләрен саклый.

Революциягә кадәр 50-70 хуҗалык (200 ир-ат) мәхәллә төзи алган. Андый авылларда агач мәчет булган, ә мәктәп бик еш гына мулла хуҗалыгында аерым йортта яки мулла яшәгән йортның бер ягында урнашкан булган. Аерым мәктәп бинасы тоту өчен авыл халкының акчасы җитмәгән. Зур мәхәлләләрдә исә мәктәп биналары булган.

Гошер сәдакасы (җыелган уңышның уннан бер өлеше) мәхәлләләрдәге муллаларга бүлеп бирелгән (көшел яисә тартылган ашлык белән түләнгән). Шунлыктан елына ике тапкыр мулла сәүдәгәргә әверелгән. Ул көшелләрне шул килеш яисә кеше яллап үзенең ындыр табагында суктырып, ашлык итеп базарга чыгарып саткан. Корбан бәйрәме үткәч мулла икенче тапкыр сәүдәгәргә әйләнә торган булган: чалынган терлек тиреләренең һәммәсе дә авыл мулласына бирелгән. Тик гошер сәдакасын бирү бөтен җирдә дә таралмаган булган. Мондый традиция булган җирдә муллалар яхшы яшәгән. Ә кайбер төбәкләрдә, гомумән, муллаларның махсус керем чыганагы булмаган. Гадәттә, мулла кеременең күп өлешен сәдака тәшкил иткән.

Игенче җәмгыяте, җыенда карар чыгарып, еш гына муллаларны дәүләт салымынан азат иткән, үз өстенә алган. Шулай ук имам, мәэзингә имана җире бүлеп бирелгән. Кечкенә авылларда, ярлы мәхәлләләрдә мулла иген иккән, мал асраган, умарта тоткан һ.б. Иген уңмаган, ачлык елларында ярлы-ябагайга ярдәм итеп, аларны үзенә бәйле итеп, батрак итеп хуҗалыкта файдаланган, авылдашларын эксплуатацияләгән дин әһелләре дә булган.

Империя чорында зәкят безнең җирлектә киң таралган күренеш булмаган. Аны XIX гасыр азагында Казанда кертә башлаганнар. Фабрикант Акчуриннарның акционерлык җәмгыяте Уставында: "Еллык табышның 2,5 процентын дини чыгымнарга тотарга", дип язылган булган. Бүген дә шушы тәҗрибәне кулланып була. Хәзерге юридик затлар Уставларына "дини ихтыяҗ"ларга 2,5% табышны бирү дигән пункт кертсәләр, бу - безнең ил шартларында зәкятне рәсмиләштерүгә тиң адым булыр иде. Элек Диния нәзарәтендә хәзерге кебек Зәкят фонды булмаган. Ә менә вакыфларны күзәтү оешмасы эшләгән. Күчемле һәм күчемсез милек мәчетләргә, мәктәпләргә, мәдрәсәләргә рәсми рәвештә бирелгән. Россия хөкүмәте вакыфны танымаган, шуңа күрә рәсми кәгазьләрдә бүләк ителгән милек "мәчеткә (мәктәп, мәдрәсә) бирелгән күчемсез милек" булып йөргән, ә мөселманнар аны "вакыф" буларак биргән.

*Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,*
*ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының урта гасырлар тарихы бүлеге мөдире*

(Галим белән әңгәмәне газетабызның алдагы саннарында тәкъдим итәрбез.)

# *Татарстан мөфтияте җитмеш китапханәчек әзерләде*

**28 декабрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Россиядә беренчеләрдән булып, Татарстандагы төрмәләр, төзәтү колонияләре гыйбадәтханәләренә һәм республикабызның мөселман белем бирү учреждениеләренә бушлай тапшыру өчен, традицион хәнәфи мәзһәбенә туры килә торган китаплар тәкъдим итте.**

Мөфтиятнең фән һәм мәгариф бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов билгеләп үткәнчә, элегрәк: "Бушлай китаплар юк", - дигән сүзләрне дә ишетергә туры килгән. Хәзер алар өчен җитмеш китапханәчек (барлыгы 700 китап) әзерләнгән. Алар арасында "Гыйбадәте исламия", "Расскажи мне об Исламе", "Намаз посланника Аллаха" китаплары һәм 2012 елга чыгарылган "Фатиха" календаре да бар. "Бу башлангычка мөхтәсибәтләр, җирле дин әһелләре, хәйриячеләр кушылыр дип өмет итәбез", - дип белдерде ул.

Мөфтиятнең мәгариф һәм фән бүлеге белгече Айдар хәзрәт Кәрибуллин сүзләренә караганда, әлеге китаплар мәдрәсәләргә һәм мәчетләр каршында эшләп килүче курсларга таратылачак. "Курсларда укытучылар безгә берничә мәртәбә шушы китапларны бирүне сорап мөрәҗәгать итте. Бу уку-укыту мәсьәләләрен уңай хәл итәргә ярдәм итә. Чөнки барлык мәчетләр каршында да китапханәләр юк. Шул уңайдан, бу бик кирәкле гамәл булып тора", - диде ул.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе белән элемтәләрне координацияләү буенча бүлек башлыгы Айрат хәзрәт Зарипов билгеләп үткәнчә, төрмәләр гыйбадәтханәләрендә имамнар куелган, алар белән эш алып барыла, кирәкле китаплар бирелә һәм өйрәтелә. "Максатыбыз - алар төрмәдән әхлакый яктан яхшы мөэмин-мөселман булып чыксын. Һәрхәлдә, аларның күзендә нур бар", - диде А.Зарипов, бу юнәлештә Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсендә көндәлек эш алып барылуын белдереп. Бу идарә белән мөфтият арасында махсус килешү дә имзаланган.

Айрат Зарипов сүзләренчә, төрмәдә дингә килүчеләр арасында тәртип бозучылар юк. Татарстан төрмәләреннән иреккә чыгучыларның ун проценты гына кабат рәшәткә артына эләгә икән. Ә Россия буенча бу күрсәткеч күпкә зуррак.

*Римма ГАТИНА*
*Чыганак: www.tatar-inform.ru*



# 2012 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

*(Мөселман ай календаре буенча 1433-1434 һиҗри еллар)*

**20 ГЫЙНВАР** - Һиҗрәт кичәсе көне. Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе - һиҗри ел исәбе башлана.

**4 ФЕВРАЛЬ** - Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе - Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер-сәдака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**21 МАЙ** - Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (һиҗри буенча - 310, милади буенча 922 ел).

**22 МАЙ** - мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ (гомрә) кылына.

**24 МАЙ** - Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич - Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ белән Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе.

**16 ИЮНЬ** - Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә - Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**21 ИЮНЬ** - дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча сигезенче ай - Шәгъбан ае башлану көне.

**4 ИЮЛЬ** - Бәраәт кичәсе, ягъни "ләйләтул-Бәраәт". Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**20 ИЮЛЬ** - изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.

**14 АВГУСТ** - Рамазан аенда иң кадерле кичә - Кадер кичәсе.

**19 АВГУСТ** - Гайдел-фитыр, ягъни Ураза бәйрәме.

**24 ОКТЯБРЬ** - Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**25 ОКТЯБРЬ** - Гайдел-Әдъхә, ягъни Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстандагы барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**26, 27, 28 ОКТЯБРЬ** - Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**15 НОЯБРЬ** - 1434 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**24 НОЯБРЬ** - Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**Төзүче - Абдулла хаҗи ДУБИН**

## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 31.12.2011 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:13 | 16:19 | 17:49 |
| *Якшәмбе* | 1.01.2012 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:14 | 16:20 | 17:50 |
| *Дүшәмбе* | 2.01.2012 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:15 | 16:22 | 17:52 |
| *Сишәмбе* | 3.01.2012 | 7:42 | 09:12 | 13:02 | 15:16 | 16:23 | 17:53 |
| *Чәршәмбе* | 4.01.2012 | 7:42 | 09:12 | 13:02 | 15:17 | 16:24 | 17:54 |
| *Пәнҗешәмбе* | 5.01.2012 | 7:41 | 09:11 | 13:02 | 15:17 | 16:26 | 17:56 |
| *Җомга* | 6.01.2012 | 7:41 | 09:11 | 13:02 | 15:19 | 16:27 | 17:57 |
| *Шимбә* | 7.01.2012 | 7:41 | 09:11 | 13:02 | 15:19 | 16:28 | 17:58 |

# Мөселманча Яңа ел

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

"Яңа ел мөселманнар, христиан вә башка дин әһелләре өчен дә бәйрәм түгел. Ул дөньякүләм масштабында уздырыла һәм дәүләт тарафыннан да бәйрәм көннәре исәбенә керә. Шуңа күрә без бу көнне күп котлаулар, өстәмә ял көннәре, елмаю һәм яхшы кәеф белән үткәрәбез. Тәнебезгә вә рухыбызга файдалы булган актив ял, туганнарны зиярәт итү, кунак чакыру, бүләкләр бирү һәм якыннарыбызны котлау - ислам дине тарафыннан тыелмаган, киресенчә, яхшы гамәлләр санына керә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Гамәлләребезгә ниятkә күрә хисап бирәчәкбез", - дип әйткән. Икенче бер хәдистә: "Бер-берегезне бүләкләгез - арагызда мәхәббәт тойгысы артсын, ныгысын", - диелә. Ниятебезне камилләштереп дөрес юнәлештә кулланcак, бу бәйрәм көннәре дә безнең яхшы гамәлләрдән саналыр, Иншә Аллаһ!" - дип җавап бирә хәзерге заман галиме, имам-хатыйб Шамил Рифат улы Галәветдин.

Тагын бер ислам галиме: "Кеше бирелгән вакытының кыйммәтен белсен. Хәтта бер мизгелен дә сарыф итмәсен. Максатларны дөрес куеп сүзләрендә вә гамәлләрендә Аллаһы Тәгаләгә якынаю юлларын эзләсен", - дигән.

Без вакыт җитмәүдән зарланабыз яисә ял аз эләгү сәбәпле Коръәнне вә китапларны аз укыйбыз, шул исәптән гыйлемебезне үстерүдә кыенлыклар туа. Кайберәүләр хәрам ризык ашап, исерткеч эчемлекләр эчеп, гаиләләр таркалып, бер-берсенә кул күтәргәндә, без, җәмәгать, китап укыйк, күрше-күләмне, якын дусларыбызны кунакка чакырып, ислам диненең гүзәллеген аңлатыйк, пәйгамбәребезнең (сгв) төп вазифасын үз тормышыбызда чагылдырыйк!

Шул исәптән, тыелган гамәлләрдән тыелып, булган мөмкинлекләрне кулланып, Аллаһы Тәгаләгә якынаерга язсын! Амин.

***Рүзәл КӘРИМОВ***
***Чыганак: www.altinurta.ru***

# ЯҢА ЕЛГА ӨР-ЯҢА ПЛАННАР БЕЛӘН!

**Елның-елында Балтач мөхтәсибәте ел тәмамлану, уңышларны барлау, фидакарьләрне зурлау, хәл ителмәгән мәсьәләләрне чишү юлларын билгеләү өчен җыен-бәйрәм үткәрә.**



Җыен авыллардагы мәчетләрдә укыту-тәрбия мәсьәләләренең торышына, әхлак мөгаллимнәренең эшләренә анализ ясый, халык белән эшләүнең үтемле алымнарын ачыклый. Гомумән, биредә уңышларны барлап, ирешелгәннәргә канәгатьләнеп кенә калмыйча, һәр борчыган сорауны, килеп туган кыенлыкларны уртага салып сөйләшеп, хәл итү юлларын билгеләп, ачыклап була.

Әлбәттә, җыенга килгән олуг кунаклар белән очрашу-аралашу, теләк-тәкъдимнәрне җиткерү мөмкинлеге дә күңелгә хуш килә.

Быелгы җыенга Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин, Балтач муниципаль районы башлыгы Марат Зарипов, район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Вакыйф Зәкиев, Балтач кодагые Рәшидә абыстай, авыл мәчетләре имамнары, абыстайлар, әхлак мөгаллимнәре чакырылган иде.

Бер төркем кунаклар "Әссәлам" мәдрәсәсенә йөрүче нәниләр төркеменең шөгыль-дәресләрен карады. Биредә әле өч яшьтән алып алты яшькә кадәрге ундүрт бала шөгыльләнә. Коръән сүрәләрен яттан укуны бәләкәй Зәкия башлап җибәрде.

Кунаклар, нәниләрнең зирәклегенә, мөгаллимәләренең белемле, ягымлы булуларына таң калып, һәммәсенә уңышлар теләде.

Җыенны Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев алып барды. Ул авыллардан җыелган гошер сәдакаларының мул булуын куанып хәбәр итте һәм халыкка гошернең файдасын, аның мәҗбүри булуын аңлата алган имамнарга истәлек бүләкләре тапшырды.

Ә менә елның-елында гошерне иң күп җыйган (80 хуҗалыклы авылдан корылык елында да 46 капчык!) Югары Шубан авылы имамы Гаптерәис хәзрәт "Халыкка хезмәт өчен" медаленә лаек булды.

Мәгълүмат ташкыны күп булганлыктан балаларга әхлак тәрбиясе бирү бик мөһим. Бу уку елыннан Урта Көшкәт, Чепья урта мәктәпләрендә дә православие диненә нигезләнгән әхлак кануннары өйрәтелә башлады. Димәк, төрле дин әһелләренең һәм төрле милләт, төрле диндәге балаларның толерантлыгы ныгый.

Илдус хәзрәтнең Балтачка беренче генә килүе түгел. Әле мөфти булганчы ук ул Шубан төп мәктәбендә әхлак дәресләрен карап, мөгаллимнәр эшчәнлеген югары бәяләгән иде. Мөфти итеп сайлангач та районнарга сәяхәтен Балтач районы мөселман балалары сабантуеннан башлады. Шуңа ул Балтачка кайтуын туган ягына кайтуга тиңләде. Бәйрәмнең безнең районга гына хас күркәм гамәл булуын белдерде. Әхлак мөгаллимнәренең елына республикакүләм дүрт-биш ачык дәрес үткәрүләрен батырлыкка тиң чара, дип атады. "Киләчәктә хәерле буын үссен, - дип тырышып йөрүегез өчен рәхмәт. Димәк, "Диннәр тарихы"н өйрәтүгә сезнең район әзер", - диде ул.

Җирле хакимият белән килешеп эшләү - алдан күрүчәнлек нәтиҗәсе. Дәүләт вәкилләре дә дингә килә. Гаеттә җитәкчеләрнең катнашуы "Аллаһ каршында барыбыз да тигез", дигән фикерне куәтли. "Без дәүләт белән бер юлдан барабыз", - диде Илдус хәзрәт, чыгышын тәмамлап. Безнең районда мәчетләрнең коммуналь түләүләрен күмәк хуҗалыклар күтәрә.

Марат Илшат улы дин юлындагыларның барысына да үтә катлаулы, акыл, фикер тирәнлеге сорый торган хезмәтләре өчен рәхмәтен белдерде. "Халык иманлы булса, җәмгыятебездәге социаль авырулар (фахишәлек, эчкечелек, наркомания) юкка чыгар", - диде ул, әхлак мөгаллимнәре, имам, абыстайларга мөрәҗәгать итеп.

Әхлак мөгаллимнәре берләшмәсе җитәкчесе Илзирә Мортазина 22 мөгаллимнең һәркайсы үз хезмәтен фәнни югарылыкта, нанотехнологияләр кулланып, республикакүләм ачык дәрес дәрәҗәсендә башкаруын белдерде.

Фикер алышулар, киңәш-табыш итү, Рәшидә абыстай Исхакыйның вәгазьләрен тыңлый-тыңлый бәйрәм мул табын артында дәвам итте.

Менә шундый файдалы, мәгънәле, эшлекле узды ел йомгакларына багышланган җыен.

Яңа 2012 елга Аллаһның ярдәме белән өр-яңа планнар, хезмәт дәрте, иҗади хыяллар белән аяк басабыз. "Изге эшебездә ярдәмче булсаң иде", - дип Ходайга ялварабыз.

***Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА, Балтач районы Шубан төп мәктәбенең югары категорияле әхлак мөгаллимәсе, хезмәт ветераны***

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №20 (117) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-520.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 29 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклагыз!**